| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НОВОЗАРЕЧЕНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯНА ЗАРЕЧЕНСК<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«03» июнь 2019нче ел. № 113

Яңа Зареченск авылы

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы
Яңа Зареченск авыл җирлеге Советының
2014 нче ел 14 нче ноябрендәге 74 нче номерлы
"Җир салымы турында”гы карарына
үзгәрешләр кертү турында
(үзгәрешләр белән 2015 елның 11 июлендәге 47 санлы,
23.06.2017 нче елның 23 нче июнендәге 45 нче санлы карарлары)

«Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 9 статьясына үзгәрешләр кертү турында " 15.04.2008 елдагы 63-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Яңа Зареченск авыл җирлеге Советы карар чыгарды.:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге Советының 14.11.2014 ел, №74 «Җир салымы турында» гы карарына (Яңа Зареченск авыл җирлеге Советының 11.7.2015 ел, №47, 23.06.2017 ел, № 45 карарлары белән кертелгән үзгәрешләргә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

2 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән), шулай ук «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2017 нче елның 29 нчы июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,3%.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Новозареченск авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2020 нче елның 1 нче гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында рәсми бастырып чыгарылган көннән бер ай иртәрәк түгел (http://pravo.tatarstan.ru).

Башлык,
Яңа Зареченск авыл җирлеге Советы Рәисе С.Н. Багижева